| “Килешенде”<br>“42 нче урта гомуми белем мәктәбе”<br>Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең директор урынбасары<br><br>__________________ / Г.С. Губанова/<br><br>“ ” 2020 ел | “Расланды”<br>“ 42 нче урта гомуми белем мәктәбе”<br>Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе директоры<br><br>_________________ /С.Е. Насыйбуллина/<br><br>Приказ №_______<br>“ ” 2020 ел |
| --- | --- |

Казан шәһәре Идел буе районы “42 нче урта гомуми белем мәктәбе”
Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең
беренче квалификацион категорияле ана (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы
Усманова Гөлфия Мәгъруф кызының
мәктәп этнографик музеенда эшләүче
“Халкым хәзинәләре” түгәрәгенең эш программасы

Программаның юнәлеше : рухи-әхлакый
Программаның үтәлеш вакыты: 1 ел
Укучыларның яше: 13-14

Педагогик киңәшмә утырышында каралды
Беркетмә №__________________________2020 ел

2020-2021 уку елы

**“Халкым хәзинәләре” түгәрәгенең эш программасына аңлатма язуы.**

Төп гомуми белем бирүнең ФДББС шартларында дәрестән тыш эшчәнлек түбәндәге **норматив документлар** һәм материалларга нигезләнеп оештырыла:

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартларын керткәндә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру турында» хаты, 12 май 2011 ел, №03296;

– СанПиН 2.4.2.2821-10 «Гомуми белем бирү оешмаларында укыту шартларына һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр»;

– СанПиН 2.4.4.1251-03 «Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр»;

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия бирү компонентын үстерү Программасының юнәлеше турында» хаты, 13 май 2013 ел, № ИР-352/09;

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия бирү компонентын үстерү Программасын тормышка ашыруда чаралар исемлеген формалаштыру буенча тәкъдимнәр турында» хаты, 12 июль 2013 ел, № 09-879;

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Дәрестән тыш эшчәнлек һәм өстәмә гомуми белем бирү программасын тормышка ашыру турында» хаты, 14 декабрь 2015 ел, № 09-3564.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгәнчә, дәрестән тыш эшчәнлек белем бирү һәм тәрбия процессының аерылгысыз бер өлеше һәм укучыларның буш вакытларын оештыруның бер формасы булып тора. Бүгенге көндә дәрестән соң эшчәнлек дәрестән соңгы вакытта укучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндереп оештырыла торган эшчәнлек итеп күзаллана. Дөрес оештырылган дәрестән тыш эшчәнлек системасы укучының конкурентлылыкка сәләтлелегендә чагылачак өлкә булып тора.

Татар халкының мең елларга сузылган тормышында тупланган тәҗрибәсе, гадәтләре, кешене шәхес итүче сыйфатлары, бай тарихы, тәрбия зиннәтләре бар. Шуларга мөрәҗәгать итү тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген көчәйтә. "Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка шәхес, ә шәхестән башка халык - тарихсыз"- дип әйтелә халыкта. Бүген халкыбызның милли традицияләрен торгызу, саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру өчен мөмкинлекләр зур.

Кешелек туплаган рухи байлык, әдәп- әхлак кагыйдәләрен үтемле итеп җиткерү өчен әби-бабайларыбызның, төрле авырлыклар белән яшәүләренә карамастан сынмавы, сабыр , инсафлы, мәрхәмәтле булып калуын җиткерү кирәк. Татар халкының уй, холкы, фикере, барлык йолалары, гореф-гадәтләре, традицияләре - үзе бер тәрбия ысулы булуын күрсәтә. Аларны өйрәнү балаларның рухи үсешенә этәргеч була. Баланың гаиләдә, коллективтагы тәрбияви нормалары, кагыйдәләре халык педагогикасына салынган. Халкыбызның үткәне халык авыз иҗаты үрнәкләрендә, аның археологик казылмаларында, этнографик традицияләрендә күренә. Традиция - ул милләтнең рухи һәм хезмәт тәҗрибәсен буыннан буынга тапшыру төре. Халык мәдәнияты - ул милләтебезнең йөзе, рухи хәзинәсе, җәмгыятьнең байлыгы. Баланы кече яшьтән үк ата – бабаларыбызның бай хәзинәсенә нигезләнгән һәм мең еллар буена тупланып, камилләшеп килгән милли гадәт, йолаларыбыз, гаилә, әдәп кануннары нигезендә тәрбияләү зур әһәмияткә ия. Бала аңына үз халкының үсеш тарихын, мәдәниятен, милли үзенчәлекләрен, хәзерге көндәге халәтен, дөнья халыклары арасында тоткан урынын, зыялылары, галимнәре, мәдәният һәм спорт эшлеклеләре, үз төбәгенең тарихы һәм күренекле шәхесләре турындагы мәгълүматны, гаиләсенең «нәсел агачы»н, гореф-гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен үз туган телендә сеңдергәндә генә анда үз милләтенә хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләнә.

Түгәрәкнең эш программасына татар халкының гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәр, йола уеннарын, халык авыз иҗаты үрнәкләрен чагылдырган материаллар тупладым. "Сабантуй", " Нардуган","Сөмбелә", "Нәүрүз" бәйрәмнәрен керттем. Җырлы-биюле уеннар, табышмак, мәкальләр өйрәнүне максат итеп куйдым. Халык йолалары, традицияләре, фольклор аркылы бала шәхесендә олыларга карата хөрмәт, табигатькә сакчыл караш, үзара хөрмәт, ярдәмләшү тәрбияләнә.

Кешеләрнең үз-үзләрен тоту кагыйдәләр җыелмасын тәшкил итүче сөйләм этикеты халыкның мәдәнилек дәрәҗәсен билгели торган иң мөһим өлешләрнең берсе булып тора. Сөйләм әдәбе кагыйдәләре милли традицияләргә һәм гореф- гадәтләргә таяна.

Гомуми педагогика фәненең бер тармагы булып, музей педагогикасы тора. Аның төп максаты: укучы шәхесен күпкырлы музей эшчәнлегенә тартып, иҗади үсешенә мөмкинлекләр, шартлар тудырып, гражданлык, патриотик, әхлак тәрбиясе бирү. Мәктәп музейлары туган йортка, гаиләгә, Ватанга, өлкәннәргә ихтирам хисе, батырлыкка омтылыш тәрбияли, намуслы вөҗданлы булырга өйрәтә. Монда укучы белем алып кына калмый, еллар дәвамында тупланган тарихи тәҗрибәне өйрәнә. Музейның күпкырлы эшчәнлегенә тарту аша укучы шәхесенә үсү өчен шартлар тудырыла. Түгәрәк программасында музей педагогикасынада зур урын бирелде. Республика, әдәбият, сәнгать әһелләренә бәйле даталар исәпкә алынды.

Түгәрәктә сәләтле балалар белән төркемдә, күмәкләп һәм индивидуаль эшләү формалары урын ала. “Рухи мирас” түгәрәге берләшмәсенә 13-14 яшьлек укучылар туплана. Түгәрәк эше атнага 4,5 сәгать исәбеннән яшь үзенчәлекләренә туры китереп планлаштырылды. Дәресләр атнага 3 тапкыр, 1,5 сәгатьтән, елга 157,5 сәгать үткәрелә.

**Максат:**

Тормышка һәр яктан әзерлекле, камил, үз милләтенең матди һәм рухи байлыкларын кайгыртучы, хәзерге шартларда үз урынын таба алырлык, белемле , культуралы , югары әхлак сыйфатларына ия булган шәхес тәрбияләү.

**Бурычар:**

- татар халкының тарихы, теле, әдәбияты, халык сәнгатенә карата ихтирам һәм хөрмәт тәрбияләү;
- шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып, һәр укучыны актив эшчәнлеккә тарту, иҗади сәләтен үстерү;
- халык җәүһәрләрен барлау, җыю: музей материалларын кабул итү, барлау, саклау буенча башлангыч белемнәрне үзләштерү;
- балаларны, гомумән, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, композиторлары, артистлары, язучылары, театры, музейлары белән таныштыру;
- халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша яшүсмерләрдә Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә карата ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү, шулай ук хезмәт тәрбиясе һәм эстетик тәрбия бирү.

Предмет буенча олимпиадалар, конкурслар укучыларның сәләтләрен ачу һәм үстерүдә эффектив чара булып тора. Гадәттә, олимпиада биремнәре мәктәп программасы дәрәҗәсеннән катлаулырак була. Шуңа күрә балаларны стандарт булмаган биремнәрне үтәүгә хәзерләү, шулай ук чит тирәлектә үзеңне иркен тотарга өйрәтү – шулай ук түгәрәк эшенең төп бурычларыннан берсе. Эшләрне мөстәкыйль башкару, фәнни-эзләнү эшчәнлеген оештыру иҗади эшчәнлекне башлау өчен мөмкинлек ача.

Түгәрәкнең юнәлеше:

- балаларның эстетик зәвыгын, иҗади фантазияләрен үстерү;
- балаларны традицияләребезгә нигезләнгән үзара аралашу культурасына өйрәтү;
- балаларның милли телен баету, туган ягыбызның гореф-гадәтләренә карата кызыксыну уяту, мәхәббәт тәрбияләү;

Әлеге программа түбәндәге универсаль уку гамәлләрен (УУГ) тормышка ашыруны күз алдында тота:

**Шәхси УУГ** баланың тормыш кыйммәтләрен, әхлакый һәм мораль нормаларны аңлавын һәм кабул итүен, аның әйләнә-тирәсендәге барлык нәрсәгә шәхси карашы формалашуны аңлауга юнәлгән.

**Регулятив УУГ** танып-белү процессы белән идарә итәргә булыша. Алар гыйлем туплау мәсьәләсен кабул итү күнекмәсен, билгеле бер эшчәнлекне оештыруны планлаштыру, тикшерү, үзгәрешләр кертүне, үтәлгән эшнең уңышлылыгына бәя бирүне үз эченә ала.

**Танып-белү УУГ** тиешле мәгълүматны эзләү һәм анализлауны, хәл итү ысулларын һәм алымнарын модельләштерүне һәм куллануны тәэмин итә.

**Коммуникатив УУГ** хезмәттәшлекне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга юнәлтелгән. Ул партнерны тыңлый һәм аңлый белүдән, мәгълүматны тулы һәм төгәл кабул итә һәм тапшыра, үзеңнең эш-хәрәкәтеңне партнер эш-хәрәкәте белән чагыштыра белүне үз эченә ала.

**Көтелгән нәтиҗәләр һәм аларны тикшерү төрләре**

- мәктәп, район, республика, күләмендә оештырыла торган конкурсларда, олимпиадаларда актив катнашырга тырышу;
- үз-үзләрен сәхнәдә матур, иркен итеп тота белүләренә ирешү;
- төрле бәйрәмнәрдә чыгыш ясау;
- Г.Тукайның туган көнендә, туган телләр көнендә, татар теле атналыгында катнашу, кечкенә күләмле әкиятләр, шигырьләр язу;
- милли уеннар, биюләр, җырлар, нәфис сүз белән чыгыш ясау.

**“Халкым хәзинәләре” түгәрәгенең календарь-тематик планы**

| № | Тема | Сәг. саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| 1 | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре.<br>Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру | 1,5 | | |
| 2 | Музейлар турында.<br>Нәрсә ул музей? Музей һәм мәктәп | 1.5 | | |
| 3 | Дөньяның иң танылган музейлары. Иң кызыклы музейлар.Укучыларның чыгышы | 1.5 | | |
| 4 | Гадәти булмаган музейлар. | 1.5 | | |
| 5 | Социомәдәни күренеш буларак музейлар. “музей” һәм “экспонат” | 1.5 | | |
| 6 | Музей эшчәнлегенең спецификасы белән танышу | 1.5 | | |
| 7 | Татар халкының мәдәни мирасын саклауда музейларның роле | 1.5 | | |
| 8 | Хәзерге заманда мәктәп музейларының роле.<br>Музейның коммуникатив функциясе | 1.5 | | |
| 9 | Музей активын сайлау һәм актив эшен оештыру | 1.5 | | |
| 10 | Музей эшчәнлегенең төп юнәлешләре белән танышу | 1.5 | | |
| 11 | Музей активы эшчәнлеген төркемнәргә бүлеп оештыру: эзләнү төркеме; лекторлар төркеме; экскурсоводлар төркеме; бизәүчеләр төркеме | 1.5 | | |
| 12 | Һәр төркемнең эшчәнлеге белән танышу | 1.5 | | |
| 13 | Шәһәрнең Милли музеена экскурсия; музей хезмәткәрләре белән очрашу; экспонатлар белән танышу; бизәлешне күзәтү һәм өйрәнү | 1.5 | | |
| 14 | Башка музейларның эшчәнлеге белән танышу. Башкалабыз музейлары | 1.5 | | |
| 15 | “Туган ил кайдан башлана?” шигырь укучылар конкурсына әзерләнү. | 1.5 | | |
| 16 | “Без булдырабыз!” Олимпиадага әзерләнү. | 1.5 | | |
| 17 | Музей экспонатларын тәртипкә китерү. | 1.5 | | |
| 18 | **Экскурсовод һөнәре**<br>Хәзерге заман социумында экскурсовод һөнәренең урыны. “Экскурсовод” һәм “экскурсия“ | 1.5 | | |
| 19 | Экскурсоводның сөйләм культурасы – мөһим профессиональ сыйфат. Сөйләм техникасы, басым, интонация | 1.5 | | |
| 20 | Экскурсовод эшендә паралингвистик чаралар (көттерү паузасы, мимика, ишарә) һәм психологик методлар | 1.5 | | |
| 21 | Экскурсоводның һөнәри осталыгы, сөйләм алымнары һәм үз-үзен тоту стиле. | 1.5 | | |
| 22 | Мәктәп музеенда: башлангыч һәм урта сыйныф укучыларына экскурсия үткәрүнең аермалары | 1.5 | | |
| 23 | Экскурсоводлар әзерләү. Текстлар язу | 1.5 | | |
| **24-25** | Шәһәр музейларына экскурсия<br>**(каникуллар)** | 3 | | |
| **26** | Музей экспонатларын тәртипкә китерү,<br>экспонатларның язуларын яңарту | 1.5 | | |
| 27 | Музейның инвентарь китабын төзү һәм аның белән эшләү тәртибен күрсәтү . Музейдагы һәр экспонатны | 1.5 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | инвентарь китабына теркәү | | | |
| 28 | Мәктәп музеенда экскурсия үткәрүгә әзерлек эше. Экскурсиянең темасы максаты, бурычлары | 1.5 | | |
| 29 | Экскурсиянең эчтәлеге., методик эшләнмәсе. | 1.5 | | |
| 30 | Экскурсиянең кереш өлеше һәм төп өлешләрен эшләү | 1.5 | | |
| 31 | Экскурсиянең йомгаклау өлешен эшләү. Тиешле чаралар сайлау: аудиофрагментлар, мультимедияле презентация | 1.5 | | |
| 32 | Репетиция ясау ( экскурсияне үткәреп карау) | 1.5 | | |
| 33 | **Милли ядкарьләр.** Татар халык авыз иҗатының этнография белән бәйләнеше | 1.5 | | |
| 34 | Санамышлар һәм сынамышлар. | 1.5 | | |
| 35 | Табышмакларның төрләре,аларның бик борынгы жанр булуын ассызыклау.Төрле табышмакларга җаваплар табу. | 1.5 | | |
| 36 | “Мәкаль-әйтемнәр иле” | 1.5 | | |
| 37 | Сөйләм этикеты. Тизәйткечләр | 1.5 | | |
| 38 | Тематик мәкальләр җыю. | 1.5 | | |
| 39 | Тизәйткечләрнең төрләре, аларны кайсы очракларда кулланырга мөмкинлеген аңлату. Балаларның иң яраткан тизәйткечләрен туплау. | 1.5 | | |
| 40 | Такмаклар ,такмазалар. | 1.5 | | |
| 41 | Такмаклы уеннар | 1.5 | | |
| 42 | Татар халык җырлары. | 1.5 | | |
| 43 | Халыкчан юнәлештә иҗат итүче төркемнәр. (А.Фәйзрахманов җит. ТР фольклор музыкасы дәүләт ансамбле) | 1.5 | | |
| 44 | Халыкчан юнәлештә иҗат итүче төркемнәр. ( Сорнай “фольклор ансамбле) | 1.5 | | |
| 45 | Халыкчан юнәлештә иҗат итүче төркемнәр. (Бәрмәнчек" дәүләт керәшен фольклоры ансамбле) | 1.5 | | |
| 46 | “Татар сүзе” шигырь укучылар конкурсына әзерләнү. | 1.5 | | |
| 47 | “Без булдырабыз!” Олимпиадага әзерләнү. | 1.5 | | |
| 48 | Риваять – легендалар. | 1.5 | | |
| 49 | Татар халкының дини бәйрәмнәре һәм йолалары. | 1.5 | | |
| 50 | Йолаларның төркемнәргә бүленеше | 1.5 | | |
| 51 | Календарь йолалар турында төшенчә. Ырымнар | 1.5 | | |
| 52 | Җир эшкәртү белән бәйле йолалар турында гомуми мәгълүмат | 1.5 | | |
| 53 | Иген үстерүгә бәйле фольклор. Нардуган, Нәүрүз, Сабан туе | 1.5 | | |
| 54 | Игенне җыюга бәйле фольклор: Сөмбелә. Өмәләр турында. | 1.5 | | |
| 55 | Каз өмәсе турында видео карап, китаплардан укып хәзерге һәм элеккеге өмәләрне чагыштыру. | 1.5 | | |
| 56 | Каз белән бәйле халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю,танышу,мәгънәсен аңлату. | 1.5 | | |
| 57 | Өмә җырлары, уеннары. (“Каурый алыш”, ”Канат | 1.5 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | сату”) | | | |
| 58 | Татарстанда “Каз өмәсе “үткәрелү турында өлкәннәрдән сораштыру, яздыру, чыгыш ясау. | 1.5 | | |
| 59 | Татар халкының көнкүреш кирәк яраклары: мендәр, ястык, юрган һ.б кулланылышы. | 1.5 | | |
| 60 | “Нәселемнең чигүле мендәрләре” | | | |
| 61 | Татар халкы кунакчылмы? Каз итеннән татар халык ашлары. | 1.5 | | |
| 62 | Конференцияләргә,конкурсларга, олимпиадаларга әзерләнү. | 1.5 | | |
| 63 | Гаилә йолалары турында гомуми мәгълүмат | 1.5 | | |
| 64 | Бала туу белән бәйле йолалар | 1.5 | | |
| 65 | Никах туе белән бәйле йолалар | 1.5 | | |
| 66 | Бәйрәм һәм йолаларның музейда чагылышы. | 1.5 | | |
| 67 | Музей экспонатларын тәртипкә китерү, экспонатларның язуларын яңарту. | 1.5 | | |
| 68-69 | Казан музейларына сәяхәт. | 3 | | |
| 70 | Музейда экспозиция эше. Музейда экспозиция эшенең кагыйдәләре һәм үзенчәлеге. | 1.5 | | |
| 71 | Музей стендлары ясау кагыйдәләре, төрле кичәләрне мультимедия белән тәэмин итү формалары. | 1.5 | | |
| 72 | Музей экспонатлары турында. | 1.5 | | |
| 73 | Ни өчен бу әйберләрнең урыны – музейда? | 1.5 | | |
| 74 | Музей әйберләрен исәпләү, аларны саклау, аларга фәнни тасвирлама бирү кагыйдәләре | 1.5 | | |
| 75 | Экскурсоводлар белән индивидуаль эш | 1.5 | | |
| 76 | Экскурсовод һәм аның аудиториясе. | 1.5 | | |
| 77 | Г. Кариев музеена “сәяхәт.” Г.Кариев исемендәге яшь тамашачы театры белән танышу. | 1.5 | | |
| 78 | Г.Кариев исемендәге яшь тамашачы театры артистлары | 1.5 | | |
| 79 | Г.Кариев иҗаты. | 1.5 | | |
| 80 | Г.Кариев исемендәге яшь тамашачы театрына экскурсия | 1.5 | | |
| 81 | Г.Кариев музей материалларында | 1.5 | | |
| 82 | Г. Кариевның тормыш юлы-музейда | 1.5 | | |
| 83 | Тукай музеена сәяхәт | 1.5 | | |
| 84 | Мәңге үлмәс-Тукай мирасы | 1.5 | | |
| 85 | Г.Тукай һәм театр | 1.5 | | |
| 86 | Г.Тукай һәм җыр сәнгате. | 1.5 | | |
| 87 | Тукай музее турында. | 1.5 | | |
| 88 | Тукай музеена сәяхәт. | 1.5 | | |
| 90 | Г.Тукай музееннан алган тәэсирләр. | 1.5 | | |
| 91 | Мәктәп музеенда Г.Тукай көннәре | 1.5 | | |
| 92 | Музей экспонатларын тәртипкә китерү, экспонатларның язуларын яңарту. | 1.5 | | |
| 93 | Музейдагы материалларны кулланып сөйләргә өйрәнү | 1.5 | | |
| 94 | Музей материаллары белән эш итәргә өйрәнү. | 1.5 | | |
| 95 | Экскурсоводлар белән индивидуаль эш. | 1.5 | | |
| 96 | Татар халкының милли киеме | 1.5 | | |
| 97 | Татар хатын-кызларының милли киеме. | 1.5 | | |
| 98 | Ир-атларның милли киеме. | 1.5 | | |
| 99 | Чигүләрдә – татар милли орнаменты. Тормыш- | 1.5 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | көнкүрештә чигү үрнәкләре. | | | |
| 100 | Проект эшләре. | 1.5 | | |
| 101 | Халкыбызның элекке бизәнү әйберләре - беләзек-төймәләр, йөзек-чулпылар һ. б. белән танышу, аларны туплау, музейның инвентарь китабына теркәү. | 1.5 | | |
| 102 | “Түбәтәем, калфагым” дип исемләнгән диспут-дәрес | 1.5 | | |
| 103 | Проект эшләрен яклау | 1.5 | | |
| 104 | Музей экспонатларын тәртипкә китерү. | 1.5 | | |
| 105 | Түгәрәк эшенә анализ, йомгак | 1.5 | | |